**Балалар бакчалары җитәкчеләре РМО беркетмәсе № 4 (Чираттан тыш)**

**Үткәрү вакыты**: 20.02.2020
**Үткәрү урыны**: Әгъбәс балалар бакчасы
**Катнашнашырга тиеш**: район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А., РМО җитәкчесе Аглямова М.В., балалар бакчалары мөдирләре, өлкән тәрбиячеләр.
**Катнашалар**: 42 бакча мөдире, 5 өлкән тәрбияче, РМО җитәкчесе Аглямова М.В., район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А.

**Тема**: Балаларны юл йөрү куркынычсызлыгына өйрәтү.

**Көн тәртибе:**
1. Ачык шөгыль һәм чара карау.
2. Мөдирнең презентациялэнгэн эш тәҗрибәсе белән уртаклашуы.
3. Балаларны юл йөрү куркынычсызлыгына өйрәтүдә ата-аналар белән эшчәнлек буенча материаллар күргәзмәсе.
4. Төрлеләр.

**Утырыш барышы**:
1 нче көн тәртибе буенча практик эшчәнлек – шөгыль каралды.
Тәрбияче Насирова Г.Ф. 1нче кечкенәләр төркеме белән шөгыль күрсәтте.
Анализ:
Тәрбияче шөгыльгә куелган бурычлары, максаты белән таныштырды, кулланган әдәбият, материалларын күрсәтте. Балалар контингенты турында әйтеп үтте.
- Байсар балалар бакчасы мөдире : "Тәрбияче эмоциональ, ягымлы. Шөгыльгә әзерлеге бай, кызыклы. Балалары тыңлаучан, матур сөйләм белән җавап бирәләр".
- Айман балалар бакчасы мөдире Ахметшина А.: "Шөгыль яшь үзенәлекләренә туры китереп алынган. Тәрбиянең үз-үзен тотышы тыныч, балалар да аңа ошап үзләрен тыныч тоталар, куп беләләр, кызыксынучан, мөстәкыйльләр"
- Пучы балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе : "Балаларның телләре аңлаешлы, гади җөмләләр белән сорауга җавап бирәләр. Шөгыль бар яклы усешнедә үз эченә алган.

2 нче шөгыль - күнел ачу. Чарага куйган максаты белән таныштырды. Ата-аналар белән эшчәнлеге турында сөйләде.
Анализ:
- Уразай балалар бакчасы мөдире : "Балалары куп беләләр, сорауларга төгәл җавап бирәләр, җөмләләрнее дөрес төзиләр. ФГОС буенча барлык өлкәнедә алырга тырышкан".
- Зөбәер балалар бакчасы мөдире Салихзянова Л.: "Чара методик яктан дөрес алып барылды, тәрбияче куп алымнар кулланып максатына иреште"
- № 7 балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе: "Күңел ачу эмоциональ, комфортлы булды, балалаар өчен бик кызыклы. Төрле өлкәләрдә интегральләшкән. Проблемалы сораулар куелды, балалар төшенчәләрне беләләр".

2, 3 көн тәртибе буенча бакча мөдире "Балаларны юл йөрү куркынычсызлыгына өйрәтүдә ата-аналар белән эшчәнлек" дигән темага презентцияле чыгыш ясады һәм материаллар күргәзмәсе белән таныштырды.

4 нче көн тәртибе буенча район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А. сөйләде. Яңалыклар белән таныштырды:
- Олимпиадный центрда "Юный эрудит" булачак, балалар белән актив катнашыгыз. Положнениясе куелачак.
- Туклану оештыруны даими тәртиптә тотарга. Конкурс була. Положениясе сайтка куелды, танышыгыз.
- Сайтларны тәртиптә тотарга, даими тикшерү булып тора. Ике теллелек сакланырга тиеш. Ст. "О языках образования" ФЗ №126 от 24.07.1998 нигезләнеп эшләргә.
- **Локаль актларны карап бетерергә, сайтларга куярга, ике теллелек саклансын.**

**Карар:**

1. Юл йөру эшчәнлегендә Әгбәс балалар бакчасын үрнәк итеп алып авыл балалар бакчаларында эшне дәвам итәргә.
2. Локаль актларны карап бетереп, сайтка урнаштырырга.

Район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист : ___________ Ахтямова А.А.
РМО җитәкчесе: _________ Аглямова М.В.
Сәркатип: ____________ Шакурова Р. Д.